**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№163** **«09» ноябрь 2019 ел.**

**Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 12 ноябрендә кабул ителгән 148 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 12 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы 148 нче номерлы карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 2015 нче елның 10 сентябрендә №182, 2018 нче елның 16 октябрендә № 117, 2019 нчы елның 20 мартында №142 кабул ителгән карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктның өченче абзацында «һәм салым ташламасына хокукны раслаучы документлар» сүзләрен «шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**Югары Пәнәче**
**авыл җирлеге башлыгы** **М.Х.Туктаров**